ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**Кама Тамагы муниципаль районынын**
**Тэмте авыл жирлеге Советы**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**Камско-Устьинский муниципальный район**

**Совет Теньковского сельского поселения**

422824,Кама Тамагы муниципаль районы,
Тэмте авыл жирлеге, Октябрь урамы, 65
тел. 31-2-60

Камско-Устьинский муниципальный район,
Теньковское сельское поселение,
ул. Октябрьская, 65
тел. 31-2-60

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

29.06. 2016 № 13

«Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә, Теньков авыл җирлеге башкарма комитеты Уставы нигезендә карар бирә:

1. «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. түбәндәге эчтәлекле 1.9, 1.10, 1.11 пунктчалар өстәргә:

«1.9. Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (9 нчы кушымта).»;

«1.10. Документларның күчермәләренең һәм алардан өземтәләрнең дөреслеген раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (10 нчы кушымта);

«1.11. васыятьнамәләр таныклыгы буенча һәм ышанычнамәләр таныклыгы буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ

регламенты (11 нче кушымта), әлеге карарга 1, 2, 3 нче кушымталар нигезендә 9, 10, 11 нче кушымталар белән тулыландырып;

1.2. «Адреслар бирү, үзгәртү һәм бетерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты» карарына 8 нче кушымтаны яңа редакциядә 4 нче кушымта нигезендә бәян итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Тәмте авыл җирлеге Башкарма комитетның җитәкчесе : И.А.Зиновьев